СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

**РЕШЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

13.11.2020 года № 3/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 26.02.2020 ел, № 53/1 карары (03.06.2020 ел № 56/2 редакциясендә) белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**11 статьяның 5 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:**

«5. Җирле үзидарә органы Аппараты, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе җитәкчесе, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, алар тиешле вазыйфада булган чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

**15 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән өстәргә:**

“Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затта Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда башкарыла. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнеш сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов